ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2018 г.Мензелинск № 1478

# Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район территориясендә муниципаль урман контролен башкару Регламенты турында

Муниципаль урман контролен тиешенчә башкару максатларында, Россия Федерациясе Урман кодексының 84, 98 маддәләре, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законының 14 маддәсе, Минзәлә муниципаль район Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район территориясендә муниципаль урман контролен башкару Регламентын расларга (Кушымта №1).
2. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы рәисе урынбасары – җир-милек мөнәсәбәтләре бүлеге начальнигы Р.С.Шакировка йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

Кушымта № 1
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты карарына
дата 27.12 2018 ел № 1478

# Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район территориясендә муниципаль урман контролен башкару Регламенты

## I. Гомуми положениеләр

1.1. Гамәлдәге Регламент Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район территориясендә (алга таба - Җирлек) урманнардан файдалану, саклау һәм урманнарны торгызуны контрольдә тоту һәм күзәтчелек итү тәртибен (алга таба – муниципаль урман контроле) билгели, урман законнарының сакланышын, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан урманнарны саклау һәм торгызу таләпләренең үтәләлешен тикшерү барышында вазифаи затларның гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Муниципаль урман контролен һәм күзәтчелеген башкару Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ УК), 06.10.2003 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ, 04.12.2006 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә Урман кодексын гамәлгә кертү турында"гы №201-ФЗ, 26.12.2008 елда кабул ителгән "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында"гы №294-ФЗ (алга таба - №294-ФЗ – Федераль законы), 02.05.2006 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы №59-ФЗ (алга таба - №59-ФЗ – Федераль законы), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 08.05.2007 елда кабул ителгән "Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләү турында"гы №273 Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.06.2007 елда кабул ителгән "Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында"гы №417 Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.06.2007 елда кабул ителгән "Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләрен раслау турында"гы №414 Карары, Татарстан Республикасының 28.07.2004 елда кабул ителгән "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ, Татарстан Республикасының 12.05.2003 елда кабул ителгән "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" гы №16-ЗРТ, Россия Федерациясенең Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 16.06.2007 елда кабул ителгән "Урманнарны тәрбияләү кагыйдәләрен раслау турында"гы №185 Боерыгы, Минзәлә муниципаль район Уставы, гамәлдәге регламент нигезендә башкарыла.

1.3. Муниципаль урман контроленең максаты – урман законнарының бозылуын кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, шулай ук муниципаль район территориясендә урман участокларыннан рациональ файдалануны башкару.

1.4. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең муниципаль район территориясендә урманнардан файдалану, саклау, яклау, урманнарны торгызу белән бәйле эшчәнлеге муниципаль урман контроле объекты булып тора.

## II. Муниципаль урман контролен һәм күзәтчелеген башкаручы затларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Вазифаи затлар муниципаль урман контролен башкарганда түбәндәге хокукларга ия:

- урман участокларыннан файдалану хокукына документларны тикшерергә;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар төзергә һәм алар белән гражданнарга, муниципаль хосусыйлыкта булган урман участокларында урманнардан файдалану, саклау, яклауны башкаручы юридик затларга тапшырырга;

- урман законнарының үтәлешен һәм ачыкланган кимчелекләрне тикшерү нәтиҗәләре белән гражданнарга, шәһәр урманнарыннан файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызуны башкаручы юридик затларга язмача хәбәр бирергә;

- муниципаль урман контролен башкаруга каршылык тудыручы гамәлләрне булдырмауда яисә кисәтүдә, шулай ук урман законнарын бозуда гаепле гражданнарны ачыклауда ярдәм итү өчен эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

-уздырыла торган тикшерү предметы белән бәйле тиешле анализлар, пробалар, караулар уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә фәнни-тикшеренү, проект-эзләнү һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә;

- федераль законнарда каралган башка хокукларны башкару.

2.2. Муниципаль урман контролен башкарганда вазифаи затлар түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

- Россия Федерациясе законнарын, юридик затларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

- муниципаль урман контроле буенча чараларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә уздырырга;

- муниципаль урман контроле буенча чараларны уздыру максатыннан юридик затлар объектларына һәм гражданнарга чыгуны бары тик вазифаи таныклыкны күрсәткән, вазифаи бурычлар үтәгән вакытта гына һәм вәкаләтле орган боерыгы нигезендә генә башкарырга;

- муниципаль урман контроле буенча чаралар уздырганда юридик затлар вәкилләренең яисә гражданнарның катнашуына каршылык тудырмаска;

- муниципаль урман контролен башкаруда катнашучы юридик затның вазифаи затларына яисә гражданнарга яки аларның вәкилләренә тикшерү предметына кагылышлы кирәкле мәгълүмат тапшырырга;

-юридик затның вазифаи затын яисә гражданнарны яки аларның вәкилләрен муниципаль урман контроле нәтиҗәләре белән таныштырырга;

- урман законнарының бозылуы ачыкланган очракта, хокук саклау органнарына һәм әйләнә-тирә мохитне һәм табигатьне саклау өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ материал төзергә вәкаләтле органнарга җибәрергә.

2.3. Муниципаль урман контролен башкару буенча үзләренә йөкләнгән функцияләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен вазифаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тоталар.

## III. Муниципаль урман контроле кагыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Муниципаль урман контроле һәм күзәтчелеге буенча чаралар №294-ФЗ Федераль законы таләпләрен саклап уздырыла.

3.2. Муниципаль урман контроле буенча чаралар кагыла торган урманнан файдаланучылар әлеге контроль таләп ителгән объектларга керүне тәэмин итәргә, тикшерү өчен кирәкле документация тапшырырга тиеш:

- урман үсентеләрен сату-алу килешүе яисә муниципаль хосусыйлыкта булган урман участогын арендага алу яки урман участогыннан бушлай срокклы файдалану килешүе;
- урман участогыннан даими (сроксыз) файдалану хокукына дәүләт теркәве турында таныклык;
- урманнарны үзләштерү проекты;
- урман декларациясе;
- башкарыла торган эшчәнлек төрләренә лицензия;
- урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестицияле проектны билгеләнгән тәртиптә расланган өстенлекле инвестицияле проектлар исемлегенә кертүне раслаучы документлар;
- юридик затның, шәхси эшмәкәрнең оештыру документлары;
- подряд килешүе;
- урман кисентесен эшкәртү буенча технологик карта;
- эш вакытын учетка алу табеле яисә эшләрне башкару наряды.

3.3. Муниципаль урман контролен башкаручы затларның законлы таләпләрен үтәмәве, яисә аларга йөкләнгән бурычларны башкаруга каршылык тудыручы гамәлләр Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә җаваплылык таләп итә.

## IV. Муниципаль урман контролен уздырганда урманнан файдаланучыларга куелган таләпләр

4.1. Муниципаль урман контролен уздыручы орган түбәндәгеләрне контрольдә тота:

- урман участокларыннан файдалану буенча таләпләрнең үтәлешен;
- аренда килешүен вакытында төзү һәм урман участокларына хокукларга дәүләт теркәве уздыру;
- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан урман участокларын үзләштерү срокларын килешүдә билгеләнгәнчә үтәлешен;
- урман участокларыннан максатчан һәм рөхсәт ителгән төр буенча файдалануын;

- урман участокларыннан файдалану хокукын кабаттан кайтару тәртибенең үтәлешен;

- урман участокларын үз белдеге белән биләүне яисә җиргә хокукны раслаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән документларсыз файдалануны булдырмау тәртибенең саклануын;

- урман җирләренең вакытында кайтарылуын;

- урман җирләре торышы турында төгәл мәгълүмат бирелүен;

- урман җирләрен максатчан файдалану буенча яраклы хәлгә китерү, яисә туфрак катламын бозып алып барыла торган төзелеш, урман әзерләү, эзләнү һәм башка эшләр, файдалы казылмалар (киң таралган файдалы казылмаларны да кертеп) ятмаларын эшкәртү тәмамланганнан соң рекультивация уздыру, шул исәптән, хуҗалык эчендәге һәм шәхси ихтыяҗ өчен башкарыла торган эшләр буенча бурычларның вакытында үтәлешен;

- аренда түләвенең вакытында һәм дөрес башкарылуын;

- закон нигезендә урман участокларында урнаштырылган ызан, геодезия һәм башка махсус билгеләрнең булуын һәм сакланышын;

- урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә кимчелекләрне бетерү һәм җир законнары үтәлешен саклап таләпләрнең үтәлешен.

## V. Тикшерү уздыру турында мәгълүмат бирү тәртибе

5.1. Вәкиллекле орган җитәкчесе раслаган планлы тикшерү уздыруның еллык планы муниципаль районның рәсми сайтында урнаштыру аша күзәтчелек объектларына җиткерелә.

5.2. Планлы, планнан тыш тикшерү уздырган очракта, вәкиллекле органның вазифаи заты муниципаль урман контроле буенча тикшерү уздыру турында приказ проектын (алга таба – приказ) эшкәртә.

Приказ Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 елда кабул ителгән “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль закон положениеләрен башкару турында”гы №141 Россия Икътисадый үсеш министрлыгы Приказына үзгәрешләр кертү турында”гы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы Приказы буенча типовой форма нигезендә төзелә.

5.3. Планлы тикшерү уздыру турында вәкиллекле органның вазифаи заты юридик затка, шәхси эшмәкәргә муниципаль урман контроле һәм күзәтчелеге буенча тикшерү уздырылылырга кимендә өч көн кала приказның күчермәсен заказ белән почта аша хәбәр җибәрү яисә башка уңайлы ысул белән тапшыра.

5.4. Вәкиллекле органның вазифаи заты планнан тыш урынга чыгып тикшерү турында (№294-ФЗ Федераль законының 10 маддә 2 өлеш 2 пунктында күрсәтелгәнчә планнан тыш тикшерүдән башка) юридик затны, шәхси эшмәкәрне уздыру башлануга 24 сәгатьтән дә соңармыйча теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

## VI. Тикшерү уздыру сроклары

6.1. Урынга чыгып документларны тикшерү срогы (планлы, шулай ук планнан тыш) 20 эш көненнән соңара алмый.

6.2. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыруның гомуми срогы кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен елга 15 сәгатьтән артык була алмый.

6.3.Урынга чыгып тикшерү уздыручы вәкиллекле органның вазифаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яисә) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр уздыру белән бәйле аерым очракларда, урынга чыгып тикшерү уздыру вәкиллекле орган җитәкчесе тарафыннан озынайтылырга, ләкин 20 эш көненнән дә соңармыйча, кече предприятиеләргә, микропредприятиеләргә карата 15 сәгатьтән дә артык булмаган сроктабулырга тиеш.

## VII. Планлы тикшерү

7.1. Планлы тикшерүләр вәкиллекле орган эшкәртә торган еллык план нигезендә уздырыла.

7.2. Планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

- муниципаль контроль органының атамасы;
- вазифаи затның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре яисә тикшерү уздырырга вәкаләтле вазифаи затлар, шулай ук экспертлар тикшерүенә җәлеп ителгән эксперт оешмалары вәкилләре;
- тикшерелә торган юридик затның исеме яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- тикшерү максаты, бурычлары, тикшерү предметы һәм аның уздырылу сроклары;
- тикшерү уздыруның хокукый нигезләре, шул исәптән тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр;
- уздыру сроклары һәм тикшерү уздыруның максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле чаралар исемлеге;
- гамәлдәге Положениенең исеме һәм реквизитлары;
- тикшерү уздыру максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырырга тиешле документлар исемлеге;
- тикшерү уздыруның башлану һәм тәмамлану датасы.

7.3. Планлы тикшерү документ тикшерү һәм (яисә) урынга чыгып тикшерү формасында уздырыла.

## VIII. Планнан тыш тикшерү

8.1. Планнан тыш тикшерү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә Җирлекнең җирле үзидарә органнарының мәҗбүри таләпләрендәге һәм (яисә) муниципаль хокукый

актларында билгеләнгән таләпләрдәге кимчелекләрне бетерү турында моңа кадәр бирелгән язмача хәбәрне башкару срогы чыгу;

2) вәкиллекле органга гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мәгълүматлар керү:

- кеше тормышына, гражданнар сәламәтлегенә, терлекләргә, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы туу;

- кеше тормышына, гражданнар сәламәтлегенә, терлекләргә, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

- кулланучылар хокуклары бозылу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта).

8.2. Вәкиллекле органга мөрәҗәгать иткән затны ачыклау мөмкин булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук гамәлдәге регламентның 8.1 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлар булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыруга нигез була алмыйлар.

8.3. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш тикшерү әлеге юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органы белән килешенгәннән соң уздырылырга мөмкин.

8.4. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш урынга чыгып тикшерү турында приказга кул куелган көнне, тикшерү уздыруны килешү максатыннан, вәкиллекле органның вазифаи заты заказ белән почта аша яисә электрон цифрлы имзаланган тапшыру турында хәбәр язуы белән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органына планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килешү турында гариза тапшыра.

8.5. Гариза Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 елда кабул ителгән “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль закон положениеләрен башкару турында”гы №141 Россия Икътисадый үсеш министрлыгы Приказына үзгәрешләр кертү турында”гы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы Приказы буенча типовой форма нигезендә төзелә.

8.6. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килешү турында гаризага түбәндәге документлар беркетелә:

- муниципаль урман контроле буенча тикшерү уздыру турында приказның күчермәсе;

- күрсәтелгән тикшерүне уздыру өчен нигезләмәнең булуын раслаучы документлар;

- гражданнардан, юридик затлардан яисә шәхси эшмәкәрләрдән кергән мәрәҗәгатьләр, гаризаларның күчермәләре, дәүләт хакимияте органнарыннан яисә җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чыганакларыннан (басма матбугат публикацияләре, интернет-чыганаклар копияләре һәм башка

документлар)гамәлдәге регламентның 8.1 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат.

8.7. Әгәр планнан тыш урынга чыгып тикшерүгә кеше тормышына, гражданнар сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актлар билгеләнгән таләпләрнең бозылуы ачыклану нигез булып тора икән, кичектергесез чаралар күрү зарурлыгы туу сәбәпле, вәкиллекле орган прокуратура органнарын контроль буенча чаралар уздыру турында 24 сәгать эчендә планнан тыш урынга чыгып тикшерүне килешү турында гариза җибәрү аша (кирәкле документларны теркәп) тиз арада тикшерү башрларга хокуклы.

8.8. Прокурорның яки аның урынбасарының планнан тыш урынга чыгып тикшерүен килешүе яисә аны уздыруны кире кагу турындагы карарына югарыда торучы прокурор яисә суд аша шикаять белдерелергә мөмкин.

## IX. Документар тикшерү

9.1. Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларындагы оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгеләүче мәгълүматлар, мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, муниципаль контроль органнарының карарларын һәм хәбәрләрнең үтәлеше белән бәйле мәгълүматлар документар тикшерү предметы булып торалар.

9.2. Документар тикшерү уздыру барышында контроль чараны алып баручы вазифаи затлар беренче чиратта юридик затның, шәхси эшмәкәрнең вәкиллекле орган карамагындагы документларын карыйлар.

9.3. Вәкиллекле орган карамагында булган документлардагы мәгълүматларның төгәллеге нигезләнгән шик тудыра яисә әлеге мәгълүматлар юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан урман законнарының мәҗбүри таләпләренең үтәлешенә бәя бирү мөмкинлеге бирми икән, вәкиллекле органның вазифаи заты юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына документар тикшерү уздыру барышында карау өчен башка кирәкле документлар җибәрүне таләп итә. Әлеге таләпкә муниципаль урман контроле һәм күзәтчелеге буенча тикшерү уздыру турында вәкиллекле орган җитәкчесенең мөһер белән расланган приказ күчермәсе беркетелә.

9.4. Таләптә (запрос) күрсәтелгән документлар шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең, юридик затның имзасы, мөһер (булган очракта) куелган күчермәләр рәвешендә тапшырылырга тиеш.

9.5. Дәлилләнгән таләп (запрос) алган көннән 10 эш көне дәвамында юридик зат яисә шәхси эшмәкәр вәкиллекле органга таләптә күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

9.6. Документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланган яисә әлеге документлардагы мәгълүматларның вәкиллекле органда булган документлардагы мәгълүматлар белән тәңгәл килмәгән очракта, бу турыда

мәгълүмат 10 эш көне эчендә тиешле аңлатмаларны язмача тапшыруны таләп итеп юридик затка, шәхси эшмәкәргә җибәрелә.

9.7. Ачыклау бүлегенә тапшырылган документларда табылган хаталар һәм (яисә) каршылыкларга кагылышлы документлар тапшырган юридик зат, шәхси эшмәкәр моңа кадәр тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны өстәмә тапшырырга хокуклы.

9.8. Вәкиллекле органның вазифаи затлары җитәкче һәм юридик затның башка вазифаи заты, аның вәкаләтле вәкиле моңа кадәр тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы аңлатмаларны һәм документларны карыйлар. Әгәр тапшырылган аңлатмалар һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаган очракта, урман законнарының мәҗбүри таләпләре бозылу билгеләре ачыкланса, вәкиллекле органның вазифаи затлары урынга чыгып тикшерү уздыралар.

9.9. Документар тикшерү барышында әлеге контроль чараны уздыручы затның юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документар тикшерүгә кагылышы булмаган мәгълүматларны һәм документларны таләп итәргә хокукы юк.

## X. Урынга чыгып тикшерү

10.1. Документар тикшерү вакытында эшмәкәрлек эшчәнлегенең кайбер төрләрен башкара башлау һәм вәкиллекле орган карамагында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларында булган башка хәбәр язуларында булган мәгълүматның тулы һәм төгәл булуын белү мөмкин булмаган очракта, шулай ук юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген урман законнарының мәҗбүри таләпләре яисә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры килүенә бәя бирү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү уздырыла:

10.2. Урынга чыгып тикшерү вәкиллекле органның вазифаи затының таныклыгын (служебный) күрсәтүдән, җитәкченең яисә юридик затның башка вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен урынга чыгып тикшерү турындагы приказ һәм урынга чыгып тикшерүне уздыручының вәкаләтләре, шулай ук максатлар, бурычлар, урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигезләмәләр, контроль буенча чаралар төрләре һәм күләме, урынга чыгып тикшерүгә җәлеп ителгән очракта, экспертлар составы, эксперт оешмаларының вәкилләре белән, тикшерүне уздыру сроклары һәм шартлары белән таныштырудан башлана.

10.3. Җитәкче, башка вазифаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, урынга чыгып тикшерү уздыручы вәкиллекле органның вәкаләтле вәкиленә, урынга чыгып тикшерүдә катнашкан очракта, экспертларга, эксперт оешмаларына юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр куллана торган җиһазларга, шундый объектларга, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлек алып барганда файдалана торган биналар, корылмалар урнашкан территорияләргә керүне тәэмин итәргә бурычлы.

## XI. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

11.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 елда кабул ителгән “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль закон положениеләрен башкару турында”гы №141 Россия Икътисадый үсеш министрлыгы Приказына үзгәрешләр кертү турында”гы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы Приказы буенча типовой форма нигезендә вазифаи зат тарафыннан акт төзелә.

11.2. Тикшерү акты турыдан-туры тикшерү тәмамланганнан соң ике экземплярда рәсмиләштерелә, аның берсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкче, башка вазифаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, урынга чыгып тикшерү уздыручы вәкиллекле органның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында расписка белән тапшырыла.

Җитәкче, башка вазифаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, урынга чыгып тикшерү уздыручы вәкиллекле органның вәкаләтле вәкиле булмаган, шулай ук тикшерүче затның танышу турында расписка бирүдән баш тарткан яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарткан очракта, тикшерү акты заказ белән почта аша уведомление белән җибәрелә (ул вәкиллекле орган эшендә саклланучы тикшерү акты экземплярына кушыла)

11.3. Дәүләт, коммерция, служебный, башка сер сакланган мәгълүматы булган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

11.4. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен аны уздыруга прокурор органы белән килешү таләп ителгән очракта, тикшерү акты копиясе тикшерү уздыруны килешү турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү акты төзелгән көннән биш эш көне эчендә җибәрелә.

11.5. Вәкиллекле органның вазифаи заты тарафыннан тикшерүне учетка алу журналына муниципаль урман контроле исеме, тикшерү уздыруның башлану, тәмамлану даталары, тикшерү вакыты, хокукый нигезләр, максатлар, бурычлар һәм тикшерү предметы, ачыкланган кимчелекләр турындагы мәгълүматлар турында язма, шулай ук тикшерү уздыручы вазифаи затларның исем-фамилияләре, атасының исеме һәм башкарган вазифасы, аларның имзалары күрсәтелә.

11.6. Тикшерүләрне учетка алу журналы булмаган очракта, тикшерү актына тиешле язма языла.

11.7. Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылган очракта, тикшерү уздырылган затка (физик затка карата муниципаль инспектор хокуклы, ә юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә карата бурычлы) тикшерү акты белән бер үк вакытта урман законнарының бозылуын бетерү турында (бетерелү срогын күрсәтеп) язмача хәбәр бирергә.

11.8. Муниципаль контроль уздыру нәтиҗәсендә ачыкланган урман законнарының бозылуын бетерү турындагы язмача хәбәр (предписание) (алга таба – язмача хәбәр) ике экземплярда төзелә, аның берсе юридик затның җитәкчесенә, шәхси эшмәкәргә, гражданинга яисә аларның вәкилләренә тиешенчә рәсмиләштереп һәм билгеле бер гамәл кылырга вәкаләтләрне раслап, расписка белән яисә тапшыру турында уведомление белән почта аша җибәрелә, икенчесе – вәкиллекле органда кала.

11.9. Язмача хәбәр (предписание) аны алган көннән башлап кимчелекләрне бетерү өчен реаль срокларны исәпкә алып, муниципаль контроль уздыручы вазифаи зат тарафыннан билгеләнә торган срокта юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гражданин тарафыннан башкарылырга тиеш.

11.10. Тикшерү уздырылган урманнан файдаланучылар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр, яисә ачыкланган кимчелекләрне тикшерү актын алганнан соң 15 көн эчендә бетерү турында бирелгән рәсми язу белән килешмәгән очракта, тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган кимчелекләрне тулаем яисә аның аерым положениеләрен бетерү турында бирелгән рәсми язуны язмача вәкиллекле органга тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр мондый каршы килүләргә аларның нигезле булуын раслаучы документларны, яисә аларның расланган копияләрен яисә килешенгән срокта аларны вәкиллекле органга тапшырырга хокуклы.

11.11. Кимчелекләрне тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан урман законнарында билгеләнгән таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, тикшерү алып барган вазифаи затлар тикшерү актына кул куелганнан соң өч көн эчендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнарга, ә уздырылган тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча материалларны административ тәэсир итү өчен хокук бозучыларга җибәрергә бурычлы.

11.12. Тикшерү материаллары формалаштырылган эш кәгазьләре (дело) рәвешендә вәкиллекле органда саклана.

## XII. Дәүләт урман күзәтчелеген башкаручы, территориаль органнар белән муниципаль урман контролен, шул исәптән урманнарда дәүләт янгын күзәтчелеген башкаручы вазифаи затларның үзара бәйләнеше

12.1. Муниципаль урман контролен башкарганда вәкиллекле орган юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә планлы тикшерү уздыруның еллык планнарын әзерләү, №294-ФЗ Федераль законында билгеләнгән нигезләмәләр, шулай ук дәүләт урман күзәтчелеген башкаручы территориаль органнар, шул исәптән, гамәлдәге законнар билгеләгән тәртиптә, урманнарда дәүләт янгын күзәтчелеге буенча юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең планнан тыш урынга чыгуларын килешү мәсьәләләре буенча юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең урнашу урыны буенча прокуратура органнары белән үзара бәйләнештә була.

12.2. Муниципаль урман контролен башкару өчен вәкиллекле органның вазифаи затлары һәм дәүләт урман контроленең территориаль органнары

тикшерү уздырмыйча, кызыксынган органнар белән берлектә урман законнарының үтәлешенә мониторинг уздыралар, урманнарга һәм урман участокларына булган материаллар буенча тиешле мәгълүмат алмашалар.

## XIII. Гамәлдәге регламентның үтәлешен контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

13.1. Гамәлдәге регламентның үтәлешен контрольдә тотуны вәкиллекле орган җитәкчесе башкара.

13.2. Тикшерү уздыруны контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерү барышында регламентны үтәгәндә агымдагы контроль формасында, тикшерү уздыру буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклап, карарлар кабул итеп, тикшерүләрнең тулылыгы һәм сыйфаты, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар һәм гамәлдәге регламент нигезендә вәкиллекле органның әйләнә-тирә мохитне саклау бүлегенең вазифаи затлары тарафыннан саклануы һәм үтәлеше белән башкарыла.

13.3. Тикшерүләр планлы (яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм плансыз булырга мөмкин. Контроль буенча чараларны тормышка ашырганда тикшерү уздыру белән бәйле барлык мәсьәләләр, яисә аерым мәсьәләләр (тематик тикшерүләр) каралырга мөмкин. Тикшерү шулай ук гариза тапшыручының конкрет мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә уздырылырга мөмкин.

13.4. Вәкиллекле органның вазифаи затлары функцияләрне, вазифаи бурычларны тиешенчә башкармаган, тикшерү барышында хокукларны бозып гамәлләр кылган (берни дә эшләмәгән) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

13.5. Россия Федерациясе законнарын, гамәлдәге Положениене бозуда гаепле затларга карата күрелгән чаралар турында, әлеге чаралар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә вәкиллекле орган хокуклары һәм (яисә) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача хәбәр бирә.

## XIV. Вазифаи затның гамәлләренә (гамәл кылмаган), шулай ук гамәлдәге Положениене башкарганда аның кабул иткән карарына шикаять бирү тәртибе

14.1. Муниципаль урман контролен башкарганда тикшерү уздырылган затларның хокуклары түбәндәгечә:

-тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм үзеңнең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуың, аның белән, шулай ук вәкиллекле органның вазифаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашу яисә ризалашмау турында тикшерү актында күрсәтергә;

- вәкиллекле органның вазифаи затларының тикшерү барышында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (чара

күрмәвенә) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд аша шикаять белдерү.

14.2. Вәкиллекле органның вазифаи затларының гамәлләре (чара күрмәве), шулай ук тикшерү барышында алар кабул иткән карарлар өчен вәкиллекле органның җитәкчесенә шикаять белдерергә мөмкин. Гариза бирүченең язмача мөрәҗәгате әлеге мөрәҗәгать теркәлгән көннән 30 көн эчендә карала.

14.3. Гариза бирүчедән язмача, шулай ук телдән мөрәҗәгате яисә шикаятенең рәсми төстә керүе вәкиллекле органның вазифаи заты гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлауга нигез булып тора.

14.4. Шәхси кабул итүгә язылу вәкиллекле органга шәхсән яисә телефон аша мөрәҗәгать (гариза бирүченең шәхси кабул итүгә вакытын, датасын билгеләү теләген исәпкә алып) аша башкарыла. Кабул итүгә язучы бүлек белгече гариза бирүчегә кабул итүнең датасын, вакытын, кабул итү урынын, кабул итүче вазифаи затның исем-фамилиясен, вазифасын хәбәр итә.

14.5. Гариза бирүчеләр шулай ук үз хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуын, законга каршы карарлар турында, вазифаи затларның гамәлләре (чара күрмәүләре), гамәлдәге Положениенең положениеләре бозылуын, үз-үзләрен нәзакатьсез тоту яисә хезмәт этикасын бозылуы турында хәбәр итә алалар.

14.6. Гамәлдәге Положение нигезендә уздырылган тикшерү барышындагы гамәлләргә (чара күрмәү) шикаять бирү турында барлык мөрәҗәгатьләр гариза бирүченең мөрәҗәгать итүенә китергән тикшерү уздыру барышында гамәлләр (чара күрмәү) өчен җаваплы, кимчелекләр тудырган белгечкә карата уздырылган җаваплылык чаралары һәм гамәлләре мөрәҗәгатьләрне исәпкә алу китабында теркәлә.

14.7. Түбәндәге очраклар дәгъваны судка кадәр (судтан тыш) карауны кире кагуга нигез булып тора:

- дәгъва белдерүченең дәгъвасында җавап җибәрелергә тиешле затның фамилиясе, адресы күрсәтелмәгән;

- дәгъвада цензурасыз, мыскыллау сүзләре, вазифаи затның тормышына, сәламәтлегенә һәм милкенә, шулай ук аның гаилә әъзаларына янау бар. Вәкиллекле орган куелган сораулары белән дәгъваны җавапсыз калдырырга һәм дәгъва белдерүче затка хокуктан явызларча файдалануның мөмкин булмавын хәбәр итәргә хокуклы;

- язмача дәгъва тексты укырга яраксыз, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырга яраксыз икән, бу турыда шикаять белдергән гариза бирүчегә хәбәр ителә;

- гариза бирүченең шикаятендә аның моңа кадәр җибәрелгән шикаятьләрендә күп тапкырлар язмача җавап бирелгән мәсьәлә бар, һәм әлеге шикаятьтә яңа сәбәпләр һәм нигезләмәләр китерелми. Вәкиллекле орган җитәкчесе чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге шикаять һәм моңа кадәр җибәрелгән шикаятьләр вәкиллекле органга җибәрелгән очракта,гариза бирүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаять белдергән гариза бирүчегә хәбәр ителә:

- әгәр шикаятьтә куелган сораугa төп мәсьәлә буенча җавап дәүләти яисә федераль закон белән саклана торган башка сер саклаган мәгълүматларны фаш итмичә бирелә алмый икән, шикаять белдергән гариза бирүчегә күрсәтелгән мәгълүматларны фаш итү мөмкин булмау сәбәпле, ул куйган төп мәсьәлә буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

14.8. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре түбәндәгечә:

1) муниципаль контроль (күзәтчелек) башкарган вакытта кабул ителгән (башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (чара күрмәү) судка кадәр (судтан тыш) шикаятьләрне канәгатьләндерү, төгәлрәк әйткәндә:

- хезмәт тикшерүе барышында вазифаи бурычларның тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, вазифаи затка карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

- хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә вазифаи затларны Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле затларга карата чаралар турында әлеге чаралар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә язмача хәбәр язуы;

2) муниципаль контроль (күзәтчелек) башкару барышында кабул ителгән (башкарылган) карарлар һәм гамәлләргә (чара күрмәү) судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне әлеге карарны дәлилләнгән нигезләмә белән юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача җибәрү юлы белән канәгатьсез калдыру;

14.9. юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр муниципаль контроль барышында кабул ителгән вазифаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәү) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд аша шикаять белдерергә хокуклы.

14.10. Судларга һәм арбитраж судларга җибәрелә торган дәгъваларны бирү, карау һәм рөхсәт бирү тәртибе Россия Федерациясенең гражданлык суд эшләрен башкару һәм арбитраж судларында суд эшләрен башкару турындагы законнары белән билгеләнә.